КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2025 ел, 5 сентябрь — г.Казань — № 663

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында» 2023 ел, 29 декабрь, 1743 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында» 2023 ел, 29 декабрь, 1743 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 11 декабрь, 1132 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналарга бүлү бердәм документын һәм территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә:

2.7 – 2.9 пунктларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.7. Әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән генераль план проектын тикшерү нәтиҗәләре буенча, әгәр дә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә генераль план проекты җәмәгать тикшерүләрендә яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш булса, Вәкаләтле орган генераль план проектын тикшерү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә генераль план проекты әзерләнгән территория караган җирле үзидарә органына җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында, мондый чараны үткәрү срокларын күрсәтеп, язмача хәбәр итә.

2.8. Җирле үзидарә органы генераль план проекты буенча җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында хәбәр алган көннән алып биш эш көне эчендә җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны үткәрү турында карар кабул итә.

2.9. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр бастырып чыгаруныраслый торган материаллар, мәгълүмат стендларында җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштыру турында актларның һәм урнаштыруны туктату турында актларның күчермәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар беркетмәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, шулай ук муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бәяләмәне бастырып чыгаруны һәм рәсми сайтта һәм (яки), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, җәмәгать тикшерүләрен үткәрүне тәэмин итә торган мәгълүмат системаларында урнаштыруны раслый торган материаллар җирле үзидарә органы тарафыннан Вәкаләтле органга генераль план проекты буенча җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында хәбәрнамә алган көннән алып 45 календарь көн эчендә җибәрелә.»;

2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.15. Расланган генераль план, схема, расланган генераль планга, схемага үзгәреш кертү Вәкаләтле орган тарафыннан Системада Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда урнаштырыла.

Вәкаләтле орган генераль планны, схеманы раслау, расланган генераль планга, схемага үзгәрешләр кертү турында карар үз көченә кергән көннән алып 10 календарь көн эчендә расланган генераль планны, схеманы, расланган генераль планга, схемага кертелгән үзгәрешләрне җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру өчен әлеге документлар әзерләнгән территория караган җирле үзидарә органына җибәрә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт төренә рөхсәтләр һәм рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә рөхсәтләр бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән вакыттан алып 10 календарь көне эчендә җирле үзидарә органына җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру өчен җирдән файдалану кагыйдәләре проектын әзерләү турында хәбәр җибәрә.»;

2.5 пунктта «территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Система)» сүзләрен «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлек башлыгы җирдән файдалану кагыйдәләре проектын алган көннән алып 10 календарь көн эчендә әлеге проект буенча җәмәгать тикшереүләре яки ачык тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итә.»;

2.8 пунктта «һәм мондый проектны алган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча мондый проект буенча җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлаулар үткәрү турында карар кабул итә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр бастырып чыгаруны раслый торган материаллар, мәгълүмат стендларында җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштыру турында актларның һәм урнаштыруны туктату турында актларның күчермәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар беркетмәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, шулай ук муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бәяләмәне бастырып чыгаруны һәм рәсми сайтта һәм (яки) мәгълүмат системаларында урнаштыруны раслый торган материаллар җирле үзидарә органы тарафыннан Комиссиягә җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында җирле үзидарә органы тарафыннан хәбәрнамә алынган көннән алып 45 календарь көн эчендә җибәрелә.»;

Комиссия җирле үзидарә органыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән материалларны алган көннән алып 10 эш көне эчендә, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, җирдән файдалану кагыйдәләре проектында үзгәрешләр кертүне тәэмин итә һәм әлеге проектны Вәкаләтле органга кертә.»

2.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Вәкаләтле орган җирдән файдалану кагыйдәләрен раслау турында карар үз көченә кергән көннән алып 10 календарь көне эчендә расланган җирдән файдалану кагыйдәләрен җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру өчен әлеге документлар әзерләнгән территория караган җирле үзидарә органына җибәрә.»;

2.12 пунктта «Системада» сүзен «территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктта татар текстында «үткәрү кирәклеге турында» сүзләре алдына «оештыру һәм» сүзләрен өстәргә;

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр бастырып чыгаруны раслый торган материаллар, мәгълүмат стендларында җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштыру турында актларның һәм урнаштыруны туктату турында актларның күчермәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар беркетмәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, шулай ук муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бәяләмәне бастырып чыгаруны һәм рәсми сайтта һәм (яки) мәгълүмат системаларында урнаштыруны раслый торган материаллар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җирле үзидарә органының фикерен теркәп, оештыручы тарафыннан Комиссиягә җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында оештыручы тарафыннан хәбәрнамә алынган көннән алып 35 көн эчендә җибәрелә.»;

4.8 пунктта «шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктта татар текстында «үткәрү кирәклеге турында» сүзләре алдына «оештыру һәм» сүзләрен өстәргә;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр бастырып чыгаруны раслый торган материаллар, мәгълүмат стендларында җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштыру турында актларның һәм урнаштыруны туктату турында актларның күчермәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар беркетмәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, шулай ук муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бәяләмәне бастырып чыгаруны һәм рәсми сайтта һәм (яки) мәгълүмат системаларында урнаштыруны раслый торган материаллар, баш тартуга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча җирле үзидарә органының фикерен теркәп, оештыручы тарафыннан Комиссиягә җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында оештыручы тарафыннан хәбәрнамә алынган көннән алып 35 көн эчендә җибәрелә.»;

5.8 пунктта «шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт

хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә:

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Расланган җирле нормативлар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән срокларда территорияне планлаштыру буенча федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Вәкаләтле орган җирле нормативларны раслау турында карар үз көченә кергән көннән алып 10 календарь көне эчендә аларны җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру өчен әлеге документлар әзерләнгән территория караган җирле үзидарә органына җибәрә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән территорияне планлаштыру документларын әзерләүне һәм раслауны тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә:

2.7 пунктында «мондый документлар буенча җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны үткәрү турында карар кабул итә» сүзләрен «өч эш көне эчендә, әгәр дә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә территорияне планлаштыру документациясе җәмәгать тикшерүләрендә яки ачык тыңлауларда каралырга тиеш булса, территорияне планлаштыру документациясе әзерләнгән территория караган җирле үзидарә органына җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында, мондый чараны үткәрү срокларын күрсәтеп, язмача хәбәр итә» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Җирле үзидарә органы җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында хәбәрнамә алган көннән алып өч эш көне эчендә мондый документация буенча җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны үткәрү турында карар кабул итә.»;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр бастырып чыгаруны раслый торган материаллар, мәгълүмат стендларында җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр урнаштыру турында актларның һәм урнаштыруны туктату турында актларның күчермәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар беркетмәләре, җәмәгать тикшерүләре яки ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә, шулай ук муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бәяләмәне бастырып чыгаруны һәм рәсми сайтта һәм (яки) мәгълүмат системаларында урнаштыруны раслый торган материаллар җирле үзидарә органы тарафыннан Комиссиягә җәмәгать тикшерүләрен яки ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү кирәклеге турында җирле үзидарә органы тарафыннан хәбәрнамә алынган көннән алып 45 календарь көн эчендә җибәрелә.».

2.10 пунктта татар текстында «норматив хокукый» сүзләрен «хокукый» сүзенә алмаштырырга;

2.12 пунктта «шундый җирлек» сүзләрен «муниципаль район» сүзләренә алмаштырырга;

2.13 пунктта «15 эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алыштырырга;
2.14 пунктта «15 эш көне» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алыштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин